ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2023 елның 07 феврале** **Чистай шәһәре** **№ 54**

Чистай муниципаль районы буенча
2023 елның I кварталына торакның
гомуми мәйданының 1 квадрат метрының
уртача базар бәясе нормативы турында

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын һәм «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр союзы» Коммерциячел булмаган партнерлыгының «бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 18 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы буенча 2023 елның I кварталына торакның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясе нормативын (сумнарда) 74 337,50 (җитмеш дүрт мең өч йөз утыз җиде) сум, 50 тиен күләмендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р.Хәсәнов